ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **К А Р А Р**

08.10.2024 — № 929

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр китерүгә сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча Бердәм комиссия төзү турында» 2016 елның 22 мартындагы 367 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Җирле үзидарә органнарының аерым бүлекчәләре кадрлар составы үзгәрүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 мартындагы 367 номерлы карары (12.03.2024 №282, 16.01.2017 №58, 02.11.2018 №2358, 28.02.2019 №431, 10.07.2019 №1090, 08.10.2020 №773, 26.11.2020 №906, 30.12.2021 №1077 үзгәрешләр белән) белән расланган Биектау муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товарлар (эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә) китерүгә алар белән контрактлар төзү максатларында поставщикларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү өчен конкурслар, аукционнар уздыру һәм котировкалар соратып алу юлы белән сатып алулар башкару буенча Бердәм комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Бердәм комиссия составыннан чыгарырга:

Вәлиуллина Рамилә Шамилевнаны – район финанс бюджет палатасы рәисен, комиссия рәисе урынбасарын;

1.2. Бердәм комиссия составына кертергә:

Миннемуллин Рушан Раифовичны – башкарма комитетның икътисад бүлеге башлыгын, комиссия рәисе урынбасары.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Хәкимуллин